ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» декабря 2022 ел № 329

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы билгеләү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 14.11.2022 елның 284 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкны коммуналь хезмәтләр белән өзлексез тәэмин итү һәм кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыруны булдырмау максатларында, күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен идарә оешмасын билгеләү Кагыйдәләрен раслау йөзеннән, Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 21 декабрендәге 1616 номерлы "Күпфатирлы йортта биналар милекчеләре тарафыннан мондый йорт белән идарә итү ысулы сайланмаган яисә сайлап алынган идарә итү ысулы гамәлгә ашырылмаган, идарә итү оешмасы билгеләнмәгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы билгеләү турында» 14.11.2022 елның 284 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Карарның 2 пунктындагы 2.4 пунктчасында:

«01.11.2022 елдан» сүзләрен «01.01.2023 елдан " сүзләренә алмаштырырга.

3. «Төзелеш-монтаж предприятиесе - 184» идарәче компаниясе» ҖЧҖен әлеге карар белән таныштырырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы

Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **Р.Р. Шәрипов**